Чыганак: Ногманов, Р. Г., Хәсәнев, М. Х. ХХ йөз татар әдәбиятына культуранализ: монография / Р. Г. Ногманов, М. Х. Хәсәнев.- Казан "Дом печати" нәшр., 2008.- 224 б.

– Бәхетлеләр сәгатькә
Карамыйлар, аппагым! –
Шулай итеп без сизмәдек
Кызарып таң атканын, –

ди ул. Бу юлларны да Муса Җәлил үлем көткәндә яза, ә алар бәхет турында. «Бәхет» төшенчәсе исә мәдәниятнең төп күренешләреннән берсе. Димәк, шагыйрьгә югары мәдәнилеге, үлем фаҗигасен җиңеп, аянычлы халәтен бәхеткә әйләндерергә ярдәм итә. Тик бу сүзләрне фантазия дип карарга ярамый, чөнки кешелек дөньясында моңа охшаш мисаллар күп. Әйтик Сократ, Сенека, Джордано Бруно, Януш Корчак һ.б. шуларга керә. Бөек затларны беркем дә үлем белән куркыта алмаган!

«Җырларым» исемле шигырьдә мондый юллар бар:

Мин кабыздым җырда ялкын итеп
Йөрәгем һәм хаклык кушканны.
Җырым белән дусны иркәләдем,
Җырым белән җиндем дошманны.

«Җырым белән җиндем дошманны», – дип, шагыйрь чираттагы мәртәбә иҗат эшен, шигърият көчен дошманга каршы куя.

Кешелек дөньясының мондый фән һәм мәдәният каһарманнары яшәүдән мәхрүм ителсәләр дә, аларның гүзәл иҗат казанышлары мәңгелек.

## 2.7. С.Хәким иҗатында мәдәни фактлар күренеше

Сибгат Хәким (1911–1986) – озын әдәби иҗат юлы узган шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе һәм халкыбызның асыл заты. Ул – Х.Туфан һәм бик күп башка шагыйрьләр белән тыгыз элемтәдә торып яшәгән кеше. Шагыйрь 1968 елда язган бер шигырендә үзенең иҗади дустына карата мөнәсәбәтен менә ничек билгели:



Төнге ике. Өстәл. Кәгазь. Кара.
Яз, дим үземә, нигә тукталдың?
Язмау оят сиңа, тәрәзәдә
Уты янган чакта Туфанның.

Бу сүзләрдә тирән мәгънә бар. Әмма иң күзгә бәрелгәне аның «оят» дигән төшенчәне алга сөрүендә булса кирәк. Мәдәният белемендә, борынгы Греция акыл иясе Демокрит фикеренә таянып, «бурыч», «оят», «намус» кебек төшенчәләр мәдәнилек фактлары буларак каралалар. Димәк, С.Хәкимнең әлеге шигырендәге хисләр дә шагыйрьнең культура дәрәҗәсен билгелиләр. Алай гына да түгел, биредә аларга бөек шәхес – Х.Туфаннан үрнәк алу омтылышы да килеп кушыла әле.

Шагыйрьнең 1965 елда иҗат ителгән бер шигыренә тукталыйк. Монда аның үз иҗатында рус халкының күренекле шагыйре, мәшһүр Н.А.Некрасовтан үрнәк алуы сизелә:

Туган якта һәр тал җырлый,
Җырлый ярга нык басып;
Монда бар да үз дигәнчә,
Монда һәр тал – Некрасов.

Өзектә тагын бер кыйммәтле фикер бар. «Монда бар да үз дигәнчә», – ди шагыйрь. Димәк, сүз биредә яшәүче халыкның, табигать законнарын бозмый гына, аның белән яраклашып яши белүе хакында бара. Башкача әйтсәк, биредә экологик яктан иминлек халәте күзәтелә. Ә мондый гармония үз культура рәвешен оныткан халык яшәгән җирдә була алмый. Шигырьгә салынган яшерен мәгънә шул: халкыбыз үз мәдәни рәвешенә тугры кала. Бу шигъри юлларны Тукайча әйтсәк, болай булыр иде: «Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява».

Бер уңайдан С.Хәкимнең Тукайга, аның иҗатына булган ихтирамы турында да әйтеп үтик. 1971 елда ул болай яза:

Петербург... Пайтәхеткә Тукай
Тик бер максат белән барды күк:
Пушкинның ул, кеше күрмәгәндә,
Карасына каләм манды күк.

Бу очракта да без бөек шәхесләрдән үрнәк алу мисалын күрәбез. С.Хәкимнең 60-нчы елларда иҗат иткән әсәрләрендәге кайбер мәдәни-культурологик мәгънәле сүзләренә игътибар итик. Мәсәлән, каләмдәше Муса Җәлилгә карата сагыну хисләрен болай ирештерә:

Идел буйларында таңнар моңсу,
Моңсу хисләр ургый тирәннән.
Муса ташлап киткән көймәләргә
Сагышларым минем төялгән...

Шагыйрь Муса Җәлилне һич онытмый. Ул аны хисси моңсулык белән искә ала, үзенең дә Мусаның рухи дәвамчысы булырга тиешлеген интуитив тоемлый. Алай гына да түгел, шагыйрь изге көрәшне үзе дә дәвам итәргә омтылуын шигыре белән раслый.

«Кәшшаф дускай» (1967) исемле шигырендә ул болай яза:

Эзен бетерик һәрчак татарларга
Рифмалашып төшкән тапларның;
Тукай белән, Җәлил белән раслыйк,
Бөеклеген раслыйк татарның!

Бу сүзләрнең рус телендә тәрҗемәсе дә игътибарга лаек, чөнки ничәмә гасырлар татар халкы урынлы-урынсыз кимсетелде, мәсхәрә ителде.

На татар поклеп и пятна?
Игра с этим именем?
Да смывайте все Тукая
и Джалиля гением!

Шунысы кызык, С.Хәким, каләмдәшләре өчен кайгырып, ут йотып йөргән арада, үзенең дә эчке рухи үзгәреш кичергәнен тоемлый



башлый. Бу очракта да шагыйрьнең асыл (изге) табигате ялгышмый. Ул чын мәгънәсендә бөек рухи янарыш кичерә.

Элеккедән күп нечкәрде күңел,
Күп үзгәрде, тулы сер белән...
Үзем һаман туган якка карыйм,
Арыш ауган якка сөрлегәм.

«Элеккедән күп нечкәрде күңел...» – дип, шагыйрь үзенең рухи-мәдәни камилләшүе хакында сөйли. Чөнки шәхси культура – кешенең иң югары психик кичерешләр югарылыгына менүе ул.

С.Хәкимнең «Тукай дәфтәреннән» (1971) дигән шигырьләре арасында эчке мәдәни кичерешләре хакында тагын да ачыграк әйткән юллар бар. Мәсәлән, ул болай язган иде:

Бәрелде җан, сугылды җан ярсып,
Читлеге тар, кысан – сыймады;
Нәрсә җитми, кая омтылуым,
Кешеләргә аңлат син аны.
Гомер буе ашкынды ул шулай
Тукай чаты, «Болгар» чатына;
Язмышлардан, сагышлардан торган
Әллә нинди моңнар чакыра.

Бирεдә без, мәдәният белеменең тагын бер мәдәни факты буларак, бөек шагыйрьләр арасында гына күзәтелә торган рухи күмәклек идеясен тоемлыйбыз. Әлеге идея шагыйрь тарафыннан 1972 елда иҗат ителгән түбәндәге юлларда да дәвам иттерелә:

Иҗаты, юлы томанлы,
Йөзе дә миңа тонык...
Тонык та, серле дә булып
Яшәде миндә Блок.

Болар – рас сүзләр. А.Блок, шагыйрь әйткәнчә, серле һәм гади акыл белән төшенә алмаслык шәхес. Аның көндәлегендәге түбәндәге

сүзләр дә шуны раслый: «Оч һәм томырыл. Башка бар юллар да һәләкәт». Моны гади акыл белән аңлавы авыр. Әмма мәдәни-культурологик яктан бу аңлашыла, чөнки башта ук без «мәдәният» төшенчәсен «затның камиллеккә омтылышы» дип бәян иткән идек. Шуннан С.Хәким рус поэзиясенең «Көмеш чор» шагыйре Александр Блок белән үз тойгылары арасында тыгыз бәйләнеш барын бәян итә. Бу хикмәт – туктаусыз камиллеккә омтылыш. Әйткәннәрдән чыгып, бу юлларның русча рәвешен түбәндәгечә күзаллап була:

И поэзия в тумане,
и образ его далек...
Пусть далек он и туманен,
но в моей душе он – Блок!

Шагыйрь А. Блокны юкка гына күңел түрендә йөртмәгән икән. Кабатлап китик, А.Блок – чын шигъриятнең мистик мәгънәсен һәм бу бөек иҗат юлының асылында кеше аңының мистик сәләте ятканын ачкан шагыйрь. Заманча мәдәният белемендә мондый халәтне башкача экзистенция, яисә альтруизм дип тә атыйлар. Ә без аны, гадирәк итү өчен, шәхси мәдәнилекнең тормыштагы чагылышы дип күзаллыйк. Чөнки «мәдәнилек» төшенчәсенең асылында нәкъ шушы психологик экзистенция күренеше ята. Фәнни күзлектән чыгып фикерләсәк, бу очракта без шагыйрьнең үз аң асты (подсознание) мөмкинлекләрен гамәлдә куллануы белән очрашабыз. Мондый алым фәнни хезмәттә дә, башка иҗади мәсьәләләр чишүдә дә киң кулланыла.

Нәкъ шушындый мәдәни фактлар җәһәтеннән аның 1972 елда иҗат ителгән тагын бер шигыренә игътибар итик. Ул болай ди:

Әй, кайда син, минем изге илһам?
Әй, кайда син, иҗат ачкычы?
Тапсам, торам сикреп урнымнан мин,
Мин тап-таза, мин сау, яшь кеше!



Хәл ачык ки, биредә шагыйрь үзенең яшәү максатын иҗат эшенә күчерә һәм үзенең бөтен барлыгын-халәтен шуңа хезмәт иттерә. Шулай булмаса, аның Ватан сугышында югалган сәламәтлеге күпкә түзмәгән дә булыр иде. Ул үзен иҗат юлына ныклап беркетүе нәтиҗәсендә гомерле була алды.

С.Хәким 1975 елларда инде үзенең интуитив-интеллектуаль сәләтен иң югары дәрәҗәгә күтәрүгә ирешә. Мондый халәтне мәдәният белемендә «иң югары интеллектуаль-интуитив аң» дип атыйлар. Моңа мисал итеп шагыйрьнең композитор М.Мозаффаров истәлегенә язган сүзләрен китереп була:

Йокламадым, яздым, кәгазь, каләм
Һәм өстәлләр белән сөйләштем;
Беләсеңме, малай, мин бит бүген
Фәрештәләр белән сөйләштем...
Яшь күңелгә салган бу сүзләрнең
Алыш-биреше юк дин белән.
Җыр-иҗатта һәрчак фәрештәләр
Кирәк икән, кирәк, мин беләм.

«Фәрештәләр белән сөйләштем», – ди шагыйрь. Чыннан да, пәйгамбәрләрнең дини информация алу мөмкинлеге дә шул ук кеше психикасының аң асты эшчәнлегенә барып тоташа. Мондый очракны фәндә «кинәт ачылган хакыйкать» («откровение») дип атыйлар. Шуннан чыгып, С.Хәким кебек бөек шагыйрьләребезнең иҗатына карата без һәрвакыт ихтирамлы булырга, аның шигъри иҗатын югары дәрәҗәдә камилләшкән илаһи бер кыйммәт итеп кабул итәргә, чын шигырьнең кеше сәламәтлеге өчен файдалы булуын истә тотарга тиеш булабыз.

Шигырьнең рус теленә тәрҗемәсе болайрак:

И не спал я вовсе. Вот бумага.
И вот стол. Пишу я. Вдохновлен…
Но вот чудо: как во сне, я с ними

говорю. И ангелы кругом.
Не от веры это, не от Бога,
это просто творческий мой стиль.
Теперь знаю: творчество поэтов
не бывает без подобных дел…

Кеше олыгайган саен сагышлы халәт кичерә. Ләкин С.Хәким тормышында мондый очраклар гүзәл шигърият булып яңгырый. Аның 1978 елда иҗат иткән «Минем таныш өянкеләр» исемле шигыренә игътибар итик. Анда без бөек аһәңнәр яңгырашын очратабыз:

Сезгә эндәшми, мин кемгә
Эндәшим, өянкеләр?
Минем дә бит җитеп бара
«Картайдым» диюселәр...
...Күбәйде миндә дә тутлар
Сездәге тутлар кебек,
Ул тутлар учакта сүнеп
Бетмәгән утлар кебек.

Мондый гүзәл камиллекне хасил иткән тирән мәгънәне, югары дәрәҗәле фәлсәфәне, искиткеч моң, тиндәшсез музыка, кабатланмас хисне тагын кайсыдыр бер шигырьдә очратуы да кыен. Әлеге мисал безнең чорны Тукай, Бабич, Рәмиевләр чоры белән дә тыгыз бәйли булса кирәк. Димәк, безнең шигъри мәдәният рәвешебез шул.

Әйткәннәргә йомгак ясап, шагыйрьнең «Ак пионнар» исемле шигыреннән өзек китерик:

Җил кебек иссте гомерләр,
Су кебек акты еллар.
Яшьлеккә истәлек төсле
Утыра ак пионнар...



## 2.8. Ш.Мөдәррис иҗатына культуранализ

Шәрәф Мөдәррис (1919–1979) шигъриятенә анализны аның тәүге әсәрләреннән саналган «Тимераякта» (1933) исемле шигыреннән башлыйк. Аны иҗат иткәндә яшь шагыйрьгә 14 яшь кенә була. Шуңа да карамастан, шигырь эчтәлекле, камил төзелешле булуы белән аерылып тора.

Җәелеп ята озын кышкы елга,
Узыша-узыша шунда шуабыз;
Чыжылдатып бозны, алга очып,
Кем остарак – шуны куабыз.
Без шуабыз тимераякларда,
Чәчәкләтеп бозны, сырлатып,
Кышкы җилдән колак төпләрендә
Дөньяда юк көйне жырлатып.
Без шуабыз, безне суык алмый,
Янып тора битләр шулай да.
Без шат булмый, җирдә кем шат булсын,
Чыжлат бозны, сырлат, шу әйдә!

Шәрәф Мөдәрриснең бу шигырендә, әдәби-сәнгати һәм мәгънәви табышлардан тыш, без бик матур фәлсәфи-культурологик эчтәлеккә дә тап булабыз. Үзебезне кызыксындырган мәдәни фактларга тукталыйк.

Беренчедән, автор безгә яңа төр хәрәкәт «тууын» искәртә. Мәсәлән, моңа кадәр без «бару», «йөрү», «йөгерү» кебек хәрәкәт рәвешләрен куллансак, хәзер аларга «шуу», «очу» өстәлә.

Икенчедән, автор балалар өчен тимераякта шууның яңа мөмкинлекләрен ача. Гади шууга караганда, «чыжылдау» тавышы – боз музыкасы астында узышу күпкә күңеллерәк. Ә иң мөһиме – балалар, узышу барышында, «кем остарак – шуны куалар». Бу очракта без инде «осталык» төшенчәсе белән очрашабыз. Осталык исә мәдәни факт, чөнки ул башкалардан да осталыкны арттыруны таләп